**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында гражданнар җыены карары**

18 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау);

-Каенлык авылында торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ( кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу ,ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?».»

3. Җыен нәтиҗәләрен Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Фролово авыл җирлеге башлыгы _________ А.Т.Садриев

Гражданнар җыены секретаре _________ Т.И.Расстригина